**СОВЕТ КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, п.ж.д.рзд. Куркачи, ул. Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды бистәсе, Гагарин ур., 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**19 ноябрь 2020 ел** **№ 11**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Коркачык авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Советының 2019 елның 22 октябрендәге 135 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә (Советның 12.05.2020 № 150 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 1.6. «Гомуми нигезләмәләр» пунктын – төшереп калдырырга;

2) «Гражданнар җыенының вәкаләтләре» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.7. Әлеге Нигезләмәдә каралган очракларда, гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) составына күрсәтелгән торак пункт кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча торак пунктта, күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүгә китерүче;

2) Коркачык авыл җирлеге Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

3) Коркачык авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен гражданнар җыены гамәлгә ашыра торган җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия җирлек халкының саны җирлек Советы төзелү турындагы мәсьәлә, аның саны һәм вәкаләтләре чоры турындагы мәсьәлә буенча 100дән артык кеше тәшкил итсә;

4) Коркачык авыл җирлеге Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

5) җирлек, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр эче территориясе, муниципаль округ, шәһәр округы составына керүче яки муниципаль район чикләрендәге авылара территориядә урнашкан торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) Коркачык авыл җирлеге Советы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә;

7) җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын күрсәтү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;

8) авыл халкының тыгызлыгы түбән булган яисә барырга кыен җирлектә урнашкан җирлектә, әгәр авыл җирлеге халкының саны 100 кешедән артмаса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча;

9) авыл торак пунктында авыл торак пунктының старостасы кандидатурасын күрсәтү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пунктының старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча.

1.7.1. Авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

1.7.2. Әлеге бүлекчәдә каралган гражданнарның җыены анда торак пунктта яисә җирлектә яшәүче сайлау хокукына ия халыкның яртысыннан күбрәге катнашканда хокуклы. Торак пунктта Әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия яртысы берьюлы бергә булу мөмкинлеге булмаган очракта, составына күрсәтелгән торак пункт кергән Коркачык авыл җирлеге уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакытта этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмыйлар. Гражданнар җыенының карары гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар, 2021 елның 01 январеннән үз көченә керүче 1.7 пунктының 6 пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф. Салихҗанов